Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

11.05.2023

Менделеевск ш.

№ 289

Гаиләнең һәр әгъзасына яки
ялгыз яшәүче гражданга туры килә
торган керемнең чик кыйммәтләрен
һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче
гражданның милкендә булган
2023 елга салым салынырга тиешле
мөлкәтенең бәясен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасына, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлык эксперт-консультация советының «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2023 елның 15 февралендәге 53 номерлы хатына, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьясына һәм Россия Федерациясе Торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының боерыгына таянып Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясе чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 856116 сум;

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1712232 сум;

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 2568348 сум;

«1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 3424464 сум;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 4280580 сум;

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 5136696 сум;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 5992812 сум;

«1.1.8. Сигез кешелек гаилә өчен - 6848928 сум.

1.2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең чик күрсәткече күләме, хисап (1 нче кушымта) нигезендә:

1.2.1. Бер кеше өчен - 21307,77 сум;

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә, шәһәр хуҗалыгына һәм сәүдә бүлегенә әлеге карарның 1.1. һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдаланырга,

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында https://mendeleevsk.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров

Менделеевск муниципаль
районы Башкарма комитетының
2023 елның 11 маендагы 289
номерлы карарына кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик кыйммәтләрен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган яки ялгыз яшәүче гражданның 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәтенең бәясен билгеләү**
**МЕТОДИКАСЫ**

**1. Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:**

**СЖ = НП х РС х РЦ,**

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган, Татарстан Республикасында торак урынны сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе.

а) бер кешедән гаиләгә:

СЖ = 47 562 х 18 х 1 = 856116 сум

б) ике кешелек гаиләгә:

СЖ = 47 562 х 18 х 2 = 1712232 сум

в) өч кешелек гаиләгә:

СЖ = 47 562 х 18 х 3 = 2568348 сум

г) дүрт кешелек гаиләгә:

СЖ = 47 562 х 18 х 4 = 3424464 сум

д) биш кешелек гаиләгә:

СЖ = 47562 х 18 х 5 = 4280580 сум

е) алты кешелек гаиләгә:
СЖ = 47562 x 18 x 6 = 5136696 сум
ж) җиде кешелек гаиләгә:
СЖ = 47562 x 18 x 7 = 5992812 сум
3) сигез кешелек гаиләгә:
СЖ = 47562 x 18 x 8 = 6848928 сум

**2. Гражданның һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләменең чик күрсәткече:**

**ПД = 0,7 x СЖ x ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$ ) / (0,3 x РС)**, где

ПД - һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең чик әһәмияте;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айга кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма) 0,0096%, (11,6/12/100).

КП - кредитның бөтен срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасының һәм фатир бәясенең нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән нисбәте.

«Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2014 елның 15 февралендәге 53 номерлы «ТР бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлык эксперт-консультация советының хаты нигезендә Менделеевск шәһәрендә һәм Менделеевск муниципаль районында торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 47 562 сум тәшкил итә.

**һәр гаилә әгъзасына**
**туры килә торганның кеременең чик күрсәткечләре**
**исәп-хисабы**

а) бер кешедән гаилә
ПД=0,7x856116,00x0,0096/ (1 - (1 + 0,0096) $^{-240}$ ) / (0,3 x 1)= **21307,77 рублей**
б) ике кешелек гаиләгә:
ПД = 21307,77 x 2 = **42615,54 рублей**
в) өч кешелек гаиләгә:
ПД = 21307,77 x 3 = **63923,31 рублей**

г) дүрт кешелек гаиләгә:

ПД = 21307,77 х 4 = **85231,08** сум

д) биш кешелек гаиләгә:

ПД = 21307,77 х 5 = **106538,85** сум

е) алты кешелек гаиләгә:

ПД = 21307,77 х 6 = **127846,62** сум

ж) җиде кешелек гаиләгә:

ПД = 21307,77 х 7 = **149154,39** сум

з) сигез кешелек гаиләгә:

ПД = 21307,77 х 8 = **170462,16** сум